# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

اسلام نوری

12+

№ 2 (678) 25 гыйнвар 2019 ел (1440, Җөмәдел-әүвәл) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


## Сүз һәм гамәл



«Аң булыгыз! Сезнең яхшыгыз кем икәнлеге хакында хәбәр биримме?… Яхшыгыз шул кеше – аннан изгелек көтелер, явызлыгыннан имин булыныр. Яманыгыз шул кеше – аннан изгелек тә көтелмәс, явызлыгыннан да имин булынмас».

Күп кешеләр үзләрен яхшыга санап, башкаларга шөбһә күзе белән карасалар да, яхшы кешеләр белән яман кешеләрне аерыр өчен Рәсүлуллаһ тарафыннан сөйләнгән бу хәдистә дәрес үлчәү куелган. Үзенең яхшы кешеләрдәнме яки яман кешеләрдәнме икәнлеген беләсе килгән кеше үзен үз үлчәве белән түгел, бәлки Рәсүлуллаһның үлчәве белән үлчәп карарга тиеш. Минбарга басып: «Үзегезне хисап кылыгыз һәм гамәлләрегезне үлчәгез», – дип кычкыруда, яки шуның кебек сүзләрне тыңлап утыруда күп мәгънә юк. Мәгънә шушы сүзләрнең мәгънәләре белән мөмкин кадәр гамәл кылуда.

Дөньяның гомере кеше белән кычкырышып, дошманлык һәм көнчелек итеп торырлык дәрәҗәдә озын булмаса да, бик күпләребезнең гомерләре шундый мәгънәсез нәрсәләр белән үтә. Дөньяның бөтен хәле хыял һәм өметләрдән гыйбарәт. Әгәр кинәт берәр максат мәйданга чыкса, ул да мәңгелек түгел, бәлки бүген, яки иртәгә кулдан китә торган бер нәрсә. Хәл шулай була торып, бер-берсе белән бозылышып, бер-берсенә яман ният кылышып яшәүче кешеләр бәхетсезләр.

*Ризаэддин бине Фәхретдин.*

*(“Җәвамигуль-кәлим шәрхе” китабыннан. Фото Интернеттан алынды)*

## “Туфан” мәхәлләсенә - 25 ел



Бүгенге көндә Чаллыда 14 мәчет эшләп килә, мәхәлләләр актив эшчәнлек алып бара. Яңа шәһәрнең 4, 5, 6 нчы бистәләрен берләштергән “Туфан” мәхәлләсе 20 гыйнвар көнне үзенең 25 еллык юбилеен билгеләп үтте. Чара Ибраһим хәзрәтнең Коръән укуы һәм шәһәребез имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллинның дога кылуы белән башланып китте. Соңрак Чаллы шәһәре Башкарма комитетының җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге башлыгы Рөстәм Рафик улы Галиуллин мәхәллә кешеләренә шәһәр Башкарма комитеты һәм үзенең котлауларын белдерде, мәхәллә имам-хатыйбы Равил хәзрәт Нуруллинга шәһәребез мэры Наил Гамбәр улы Мәһдиевның Рәхмәт хатын тапшырды. Мәҗлесне дәвам итеп, Әлфәс хәзрәт бирегә җыелган халыкка кыскача гына шәһәребездәге Ислам дине тарихын сөйләде, аннары “Туфан” мәхәлләсе тормышында актив катнашкан картларга ҮДО ТР МДН мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе бүләкләрен тапшырды.

Шулай ук чара барышында Равил хәзрәт килгән кунакларны “Туфан” мәхәлләсе тарихы белән таныштырды, аеруча актив картларга Коръән китаплары бүләк итте. Мәҗлес ахырында шәһәребез казые Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев “Туфан” мәхәлләсенең 25 еллыгы белән котлады. Өйлә намазыннан соң кунаклар чәй өстәле артында җыелыштылар.

**Нияз Газизов.**

## Җан азыгы

Чаллы мөхтәсибәте каршында эшләп килүче “Хәзинә” мөселман балалар клубы шәкертләре 14 нче гыйнвар көнне өлкәннәр өчен интернат йортында булып кайттылар. 7-10 яшьлек кызлардан торган “Нур” ансамбле әби-бабайларны мөнәҗәтләр һәм күңелле, шаян шигырьләр белән сөендерде. Чыгыш азагында балалар интернатта яшәүче һәр өлкән кешегә “Рахал” кибете тарафыннан әзерләнгән татлы күчтәнәчләр өләштеләр.

Исемен күрсәтмәскә теләгән иганәчедән картлар йортына зур күләмдә кер юу порошоклары тапшырылды. Очрашудан әби-бабайлар да, балалар да бик канәгать калдылар, чәнки җылы сүзләр, елмаю – иң кыйммәтле сәдака. Очрашуны оештыруда зур тырышлык күрсәткәннәре өчен “Хәзинә” клубында эшләп килүче “Асыл зат” төркеменә, “Нур” ансамбле җитәкчесенә һәм мөгаллимәләргә зур рәхмәтебезне белдерәбез. Аллаһ разый булсын!

## ТР МДН хәбәр итә



Җөмәдел-әүвәл аеның 11 көнендә, Болгар Ислам академиясе базасында ТР мөселманнары Диния нәзарәте Пленумы утырышы уздырылды. Утырышта Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның урынбасарлары, ТР баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Спас районы башлыгы Камил Нугаев, шулай ук бөтен республикадан имам-мөхтәсибләр һәм мөфтият эшчәнлегенең барлык юнәлеш һәм оешма җитәкчеләре катнашты. Көн тәртибенә ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм аның оешмаларының 2018 елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре, 2019 елга планнар, шулай ук “ТР мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар үткәрү турында Нигезләмә”не раслау турындагы сораулар куелды.

## Түбән Камада

17 гыйнварда Түбән Кама Үзәк мәчетендә хатын-кызлар арасында Коръән уку бәйгесе узды. Анда катнашучылар өч номинациядә көч сынашты: беренче төркемгә - 3 ел белем алучылар, икенче төркемгә - 6 ел һәм өченче төркемгә 6 елдан артык белем алучылар кертелде. Миләүшә Латыйпова, Гөлсинә Галимова һәм Асия Корбиева үз номинацияләрендә җиңүче булдылар. Коръән уку бәйгесе бирегә килгән һәркемнең күңелендә тирән кичерешләр калдырды. Җиңүчеләргә Мәккәдән кайтартылган зәмзәм суын бүләк иттеләр.

## Бөгелмәдә

Бөгелмә шәһәре Үзәк мәчетендә имамнарның 2018 ел йомгакларына багышланган хисап җыелышы узды. Чарада Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казые Марат хәзрәт Мәрданшин, Бөгелмә шәһәре һәм районы имам-мөхтәсибе Рамил хәзрәт Хәснетдинов, шәһәр һәм район имамнары катнашты. Җыелыш традицион рәвештә Коръән укудан башланды. Имам-мөхтәсиб хатын-кызлар өчен оештырылган чаралар, “Яшь мөслимә” клубы эшчәнлеге, мәктәпкәчә яшьтәге сабыйлар өчен түгәрәкләр, барлык теләүчеләр өчен Коръән уку, шулай ук татар теле курслары эшләве хакында бәян итте. Ул үсеп килүче буынны рухи-әхлакый тәрбияләү, тамырларыбызны барлау, шулай ук татар телен өйрәнү мәсьәләләренә Бөгелмә мөхтәсибәте тарафыннан аеруча зур игътибар бирелүен билгеләп үтте.

# Ильяс пәйгамбәр һәм хакимнәр турында

*Бөтен галәмнәрнең Раббысы булган, без-кешеләрне акыл нигъмәте белән баетып, барлык мәхлуклардан өстен кылган, безгә һәрвакыт үзенең төрле нигъмәтләрен биреп торучы Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләгә барча мактауларыбыз, хәмед-сәналәребез, олуглауларыбыз булсын.*

Җирләргә дә, күкләргә дә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте булып килгән, пәйгамбәрләрнең соңгысы булган Мөхәммәд (с.г.в.)гә, аның гаилә әһелләренә; хак динне безләргә җиткерер өчен үзләренең җаннарын, гаиләләрен, малларын җәлләмәгән сәхабәләргә күңел түрләребездән чыккан догаларыбыз, Аллаһы Тәгаләнең сәламе һәм салаваты булсын! Әмиин!

Кадерле дин кардәшләрем! Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәрләре тарихына багышланган хөтбәләрне дәвам итәбез. Аларның тарихын өйрәнү ни өчен кирәк безгә? Нинди файда аннан? Алдагы хөтбәләрдә әйткәнемчә, пәйгамбәрләрнең тарихын өйрәнеп, без үзебезгә үгет-нәсыйхәт, тормыш сабаклары алабыз.

Бүген сүзебез бәну Исраил халкына җибәрелгән пәйгамбәрләрнең берсе - Йәсин улы Ильяс (галәйһи сәлам) турында булыр. Аның кайчан яшәве төгәл генә билгеле түгел. Бу хакта төрле риваятьләр йөри. Кайберәүләр аны Хизкилә пәйгамбәрдән соң җибәрелгән дисә, икенчеләре башка вакытны китерә. Җәмәгать, безгә аның кайчан яшәве түгел, ә тарихы мөһим.

Бу пәйгамбәрнең исеме Коръәндә ике тапкыр килә. Беренче тапкыр Аллаһы Тәгалә аны башка пәйгамбәрләр белән бергә искә ала: “Шулай ук Зәкәрьяне, Яхъяны, Гайсәне, Ильясны һидәяткә салдык, алар һәммәсе изгеләрдән”.

Ә икенче тапкыр Аллаһы Тәгалә Ильяс (галәйһи сәлам)нең тарихын “Саффат” сүрәсендә искә ала: “Ильяс та Аллаһы Тәгаләдән җибәрелгән пәйгамбәрдер”.

Ильяс (галәйһи сәлам) Дамасктан көнбатышта урнашкан Баглабак кавеменә җибәрелә. Пәйгамбәр (галәйһи сәлам) үзенең халкын потларга табынудан тыя һәм бер Аллаһка гына табынырга чакыра. Ул заманнарда Баглабак халкы «Бәгел»(Ваал) дигән потка табынган. Без моны Аллаһы Тәгаләнең менә бу сүзләрендә күрәбез. (Ул үз халкына: “Әллә сез курыкмыйсызмы?”- ди.)

Ничек сез Аллаһы Тәгаләдән курыкмыйсыз?! Потка табынасыз?! Әллә соң сезнең йөрәкләрегез катканмы? Ничек Аллаһы Тәгаләдән курыкмый шундый зур гөнаһ кылып була?! Ә бит Аллаһы Тәгаләнең нәфрәте, җәзасы бик каты. Һәм ул теләсә кайчан ирешергә мөмкин. Хәтта бу дөньяда яшәгәндә үк!

Газиз дин кардәшләрем! Арабызда яшәүче күпме кешеләр АллаһыТәгаләдән курыкмый, тәкәбберләнеп йөриләр. Аллаһы Тәгаләгә түбәнчелекләрен күрсәтмиләр. Аннан бер көн җиткәч, Аллаһы Тәгаләдән бу кешеләргә яман чирләр ирешә. Бик тиз арада бәрешеп төшәләр алар, һәм бу якты дөнья белән хушлашалар. Аллаһы Тәгалә кайберәүләрне бу дөньяда ук харап итә.

Кадерле дин кардәшләрем! Тәкъвалык – безнең динебезнең нигезе! Сорап кара әле үзеңнән, тәкъвалык бармы синдә? Ни дәрәҗәдә ул синең тәкъвалыгың? Аллаһы Тәгаләдән куркасыңмы син? Ни дәрәҗәдә куркасың?! Көннәреңне гөнаһлар кылып үткәргәндә, гомереңне намаз укымый бушка сарыф иткәндә әллә Аллаһы Тәгаләдән курыкмыйсыңмы?!

Шуңа күрә дә пәйгамбәр Ильяс (галәйһи сәлам) халкына: “Әллә сез курыкмыйсызмы?”- дип башлый сүзен. Шуннан ул болай дип әйтә: “Һәрнәрсәне күркәм сурәттә хасил итүче Аллаһы Тәгаләне калдырып, Бәгел исемле сынга табынасызмы?!”

Ильяс (галәйһи сәлам) аларның потларга табынулары ахмаклык икәнен күрсәтергә тели. Ягъни, ничек бернинди файда яки зыян китерә алмый торган потка табынырга була? Бу пот аларга түгел, үзенә дә берничек ярдәм итә алмый. Нинди ризык китерергә була аннан? Ризык бирү түгел, ул үзе ни ашый, ни сөйләшә, ни уйлый алмый. Ташка ясалган нинди дер бер сурәт кенә бит ул!!!

Һәм шул ук вакытта сез барча галәмнәрнең Раббысы булган, безне юктан бар иткән, барча мәхлукларын кайгыртучы, санап бетергесез нигъмәтләр бирүче, рәхимнәренең Рәхиме булган бер Аллаһы Тәгаләне калдырасыз!!!

Шуннан дәвам итеп, ул болай ди: «Ул Аллаһ - сезнең Раббыгыз, вә аталарыгызның Раббысыдыр».

И Аллаһның мәхлугы, син каян, ничек барлыкка килдең бу дөньяда? Әтиең, әтиеңнең әтисен кем яралткан? Кем хасил иткән бу күркәм, камил галәмнәрне? Хасил итеп кенә дә калмаган, ә бертуктаусыз кайгыртып тора. Барча нәрсәне юктан бар кылучы - Бөек Аллаһы Тәгалә! Ул безнең йөрәкләребезгә иман нурын салучы.

Әмма бу авыл халкы Ильяс (галәйһи сәлам) нең әйткәннәренә колак салмый, «Бәгел» исемле потларына табынуларын дәвам итәләр. Шуннан Ильяс (галәйһи сәлам) аларга Аллаһы Тәгаләгә генә мохтаҗ икәннәрен, һәм бу потның берничек ярдәм итә алмавын күрсәтү өчен, “Яңгырдан мәхрүм калдыр боларны”, - дип Раббысына дога кыла. Чыннан да, шуннан яңгырлар явудан туктый, бик нык корылык башлана. Күпме генә потларыннан сорасалар да, җансыз таш кисәге аларга ярдәм итә алмый, бернинди яңгыр әсәре күренми. Бик авыр була аларга. Шуннан алар ярдәм сорап, Ильяс (галәйһи сәлам) янына киләләр. Ильяс (галәйһи сәлам): “Бары тик потка табынуыгызны калдырсагыз гына Аллаһы Тәгаләдән яңгыр җибәрүен сораячакмын”,- ди. Кавеме риза була. Ильяс (галәйһи сәлам) Аллаһы Тәгаләдән яңгыр сорап дога кыла. Һәм Аллаһы Тәгалә аларга Үзенең рәхимлегe белән мул сулы яңгырларын яудыра һәм бик яхшы уңышлар бирә.

Әмма кешенең табигате Раббысын бик тиз онытучан. Әйтәләр бит, егылып төшүче самолетта бер атеист та калмый, барчасы Раббыларына дога кыла башлый. Хәвеф-хәтәрсез, исән-имин җиргә төшү белән, шунда ук Раббыларын онытып, гөнаһ кыла, исерткеч эчемлекләр эчә башлыйлар. Бәлки, син дә бүген кая барырга белмәгәнгә генә мәчеткә килеп кергәнсеңдер, Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорыйсыңдыр. Ә хәлең яхшыргач, Аллаһы Тәгаләне искә алырсыңмы?!

Бу халык та шулай эшли. Алар янә потларына табына башлыйлар. Моны күргән Ильяс (галәйһи сәлам) аларны ташлап, тау куышына китә. Кайбер риваятьләрдә ул мәгарәдә ун ел яшәгән, ә кошлар аңа ашарга алып килгән диелә. Күпмедер вакыттан соң Ильяс (галәйһи сәлам) мәгарәдән чыга. Бу вакытта элекке хакимнәре һәм шул вакытта яшәгән буын үлгән була. Ильяс (галәйһи сәлам) яңа хакимне ислам динен кабул итәргә чакыра. Аллаһы Тәгалә бу хакимнең йөрәгенә иман нурын сала һәм ул ислам динен кабул итә. Хакиме артыннан барча халкы иярә, алар ислам динен кабул итәләр. Карагыз, кавемен хак дингә китергәнче, күпме авырлыклар үтәргә туры килә Ильяс (галәйһи сәлам)гә.

Җәмәгать, бу тарихи вакыйгадан без халкы тормышында хакимнең нинди зур роль уйнавын күрәбез. Нигездә, халык җитәкчесе, хакиме артыннан иярә. Әмма кайвакыт, идарә итүчеләр үзләрен генә кайгыртып яшиләр. Андыйларны искә алучы да булмый соңыннан. Ә халкын кайгыртучы хакимнәрне күпме гасырлар үтсә дә, яратып искә алалар.

Тарихта ислам динен халкыбыз рәсми рәвештә 922 нче елда кабул итте дип килә. Әмма хаклыкта ислам дине безнең җирләрдә күпкә иртәрәк булган.

Мәсәлән, урта гасырларда яшәгән тарихчы Мөслими раславынча, Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең өч сәхабәсе Болгар җирләренә кадәр барып җиткәннәр. Икесе кайтып киткән, ә өченчесе өйләнеп бу җирләрдә яшәп калган. Әмма Шиһабетдин Мәрҗәни һәр тарихи вакыйга дәлил белән расланырга тиеш дип, бу фикерне тәнкыйтьли. Чөнки сәхабәләрнең бу җирләргә җитүен раслаучы бернинди дәлил юк. Шул ук вакытта Шиһабетдин Мәрҗани бу сәхабәләрнең безнең җирләргә җитәргә мөмкин булуларын инкяр итми. Ник дигәндә, Пәйгамбәребез (с.г.в.) янында төрки телләрне белүче сәхабә булуы һәм Пәйгамбәребез(с.г.в.)нең аны төньяк төрекләренә ислам диненә чакырып язган хаты белән җибәрүе тарихта расланган. Бәлки бу сәхабә шул хат белән җибәрелгән сәхабә булгандыр.

Ә хәзер 921 нче елга күз салыйк. Пәйгамбәребез (с.г.в.) вафатыннан соң 290 ел үтә. Ул вакытта Рәсәйнең Идел ягында Идел буе Болгары дәүләте була. Аны Алмыш хан җитәкли. Ул вакытта Алмыш хан мөселман булмый әле. Кавказ территориясендә һәм Рәсәйнең урта өлешендә хәзәрләр каганаты, көньякта Рим империясе һәм абасидлар хәлифәте була.

Алмыш хан хәлиткеч карар кабул итә. Ул Багдадның хәлифе Габдел Мутаддиргa ярдәм сорап хат яза. Һәм хатында үзе дә, халкы да ислам динен кабул итәчәген белдерә. Игътибар итегез, җәмәгать, Алмыш хан Рим империясенә дә, хәзәрләр каганатына да мөрәҗәгать итми, ә мөселманнар хәлифеннән ярдәм сорый. Габдел Мутаддир хатны алгач, аларга Әхмәт бну Фадлан җитәкчелегендә галимнәр делегациясен җибәрә. Алар безнең җирләргә бер ел баралар. Бу сәфәрдә зур делегациянең байтагы үлә, беразы гына исән кала. Шулай да 922 нче елның 21 маенда алар Болгарга барып җитәләр.

Алмыш хан бу делегацияне зур ихтирам күрсәтеп кабул итә. Кулы астында булганнарның барчасын бер өстәл артына җыеп, үзенең ислам динен кабул итүен һәм моннан соң Идел буе Болгарында ислам дине дәүләт дине булачагын игълан итә. Бу өстәлдә төрле зиннәтле сыйлар, хәтта бөркет итенә кадәр була. Әхмәт бну Фадлан бөркет ите барлыгын белгәч, хәлифкә исламда бөркет итенең тыелган булуын хәбәр итә. Алмыш хан моны ишетү белән бөркет итен өстәлдән алып куярга куша.

Бу вакыйгада хакимнең куәтле ихтыяр көченә ия булып, ныклы карар кабул итә белүе аша үз халкының тормышын саклап кала алуында безгә зур сабак бар. Ныклы карары белән Алмыш хан тарихта гасырлар буена сакланып килә торган эз калдырган. Бу бөек шәхесләр сәбәпле ислам дине буыннан буынга тапшырылып, безләргә кадәр сакланып, килеп җитте. Әлхәмделиллән! Аллаһу әкбәр!

Мин сөйләгән вакыйгада бер кызыклы факт бар - Әхмәт бну Фадлан Болгарга килеп җиткәч, бу җирләрдә мәчетләр, мәдрәсәләр күреп гаҗәпләнә. Аларның булуы безнең җиребездә ислам дине аннан да иртәрәк булуын раслый.

Әмма Алмыш хан ислам динен үз ирке белән барча халкының кабул итүенә сәбәпче була.

Аллаһы Тәгалә әйтә: “Бу өммәт дөньядан үтеп китте. Аңа үзе кәсеп иткәне, һәм сезгә үзегез кәсеп иткәнегез. Вә сез аларның гамәлләреннән соралмассыз.”

Ә хәзер үзебездән сорыйк: ата-бабаларыбыз юлын дәвам итәбезме без? Оныкларыбыз безнең кебек ата-бабалары белән горурлана алырлармы? Алмыш хан кебек ныклы ихтыяр көченә ия булган мөселманнар үстерәбезме без?

Шул сораулар хакында да уйлансак иде.

**Әбүбәкер хәзрәт Әбдиев,**
**Чаллының “Тәүбә” мәчете имам-хатыйбы.**

# Тел - олы нигъмәт

Безгә телебез Аллаһны зекер итәр, Коръән укыр, Аллаһның колларын туры юлга өндәр, Хак Тәгаләдән үзеңнең дөнья вә Ахирәт хаҗәтләреңне сорар өчен бирелгән. Әгәр без Аллаһның безгә биргән шушы олы нигъмәте - телебезне Ул кушканча файдалансак, әлбәттә, шөкеранә кылучылар булырбыз. Башкаларга яла ягып, ямьсез сүзләр сөйләр өчен куллансак, тәмугка керүебезгә сәбәпче була. Иң явыз дошманнарыбызның берсе тел икән, әйдә булган акылыбызны, ихтыяр көчебезне җыеп, аны җиңик. Берәү әйткән бит: «Картайган саен, әгъзалар, буыннарның хәле китә, кызганыч ки, аларның куәтләре нәфескә һәм телгә күчә», дип. Бу да иман зәгыйфьлегенең бер мисалы. Картайган саен, кешенең тәкъвалыгы артырга тиеш. Картаю ул - Аллаһ белән очрашуга якынаю. Акыллы кеше кем белән булса да очрашырга барганда, бүләк әзерли. Ә Аллаһ каршында изге гамәлләр генә кыйммәткә ия.

**Җәлил хәзрәт Фазлыев,**
**Татарстанның баш казые.**

# Дога кабул булсын дисәң...

«Дога» сүзе гарәп теленнән «ялвару», «сорау» дип тәрҗемә ителә, шәригатьтә исә дога ул – Аллаһка мөрәҗәгать итеп, Аннан нәрсәдер өмет итү. «Бәкара» сүрәсенең 186 нчы аятендә Аллаһы Тәгалә бу хакта болай ди: «Бәндәләрем Минем турында сораштырсалар, әйт: Мин чыннан да һәр кешегә бик якын һәм Миңа ялварып дога кылучыларга җавап бирәм, бәлки алар туры юлны табарлар».

Шулай да кайбер кешеләр: «Дога кылабыз, ләкин теләгән нәрсәләргә ирешә алмыйбыз», – дип зарлана. Дөрестән дә, ни өчен кайбер догалар кабул була, ә кайберләре юк? Ислам галимнәре дога кабул булуның кайбер мөһим шартларын билгеләп уза. Шуларның берничәсен искә алып китик.

– ***Дога*** ул – гыйбадәт, ә һәр гыйбадәт итагатьлек-тәкъвалыкка нигезләнеп, ***ихлас күңел белән кылынырга тиеш.***

– ***Дога кылганда*** рөхсәт ителгән, хәләл булган нәрсәләрне генә сорарга кирәк (Аллаһ тыйган, ягъни хәрам булган нәрсәне өмет итеп дога кылу катгый тыела). Әйтик, хәзер күпләр ниндидер максатка ирешәм дип процентлы бурыч ала яки киресенчә – процент билгеләп әҗәткә акча бирә, ягъни рибага керешә. Ә ислам дине буенча риба – катгый тыелган хәрам гамәл. Аның белән бәйле булган нәрсәләрне сорап дога кылу дөрес түгел.

- Дога кабул булсын өчен ***хәрам*** ризык ***ашамаска***, хәрам эчемлекләр ***эчмәскә, хәрам кәсеп белән шөгыльләнмәскә*** кирәк. Киң таралган күренешне – туйларда, юбилейларда һәм шуның ише башка чараларда хәмер тутырылган рюмкаларны күтәреп теләк теләү гадәтен мисалга китерергә мөмкин. Туганына яки дустына «озын гомер», «сәламәтлек», гаилә корган яшь парга «сау-сәламәт, тәртипле балалар» теләп тост әйтүче кеше үзенчә «дога кыла», чөнки кешенең саулыгы да, гомер озынлыгы да, балалар булу-булмавы да – фәкать Аллаһ кодрәтендә булган нәрсәләр. Әмма аракы эчүне тыйган Аллаһтан шул хәрамны эчкән мәлдә ничек итеп нәрсәдер сорарга мөмкин? Бер уңайдан шуны да әйтеп китәргә кирәктер: туачак баланың холкы, сәләтләре, башка шәхес хасиятләре белән бәйле булган үзенчәлекләре әтисенең орлыгында чагылыш тапкан нәсел геннары нигезендә формалашса, тәне әнисе карынында үсеп, җыелып бетсен өчен «материал» буларак шул әнисе ашаган ризык файдаланыла. Әгәр туачак баланың әтисе аракы эчсә, яхшы геннар да бозылып үзгәрә, әнисе хәрам ризык ашаса, баласының тәне шул хәрамнан туплана. Хәрамнан җыелган гәүдә исә киләчәктә хәрам нәрсәләрне эзләп, хәрам гамәлләр кылудан тәм табачак, ә әти-әнисе: «Нигә бу бала мондый булды икән, без бит аны начарлыкка өйрәтмәдек... », – дип аптырап кайгырачак, үзләренчә бала хакына дип дога да кылачак, әмма бу дога кабул ителерме һәм баланы шайтан җәтмәсеннән коткарып булырмы? Иншә Аллаһ, ләкин моның өчен бик тә, бик тә ихласлы, елый-елый дога кылырга кирәк; әмма...

– ..ниндидә булса хаталарың, гөнаһ-кимчелекләрең булуны беләсең икән, ***дога кылганчы тәүбә итәргә, Аллаһтан гафу үтенергә*** кирәк (кемнедер рәнҗеткән-үпкәләткән булсаң – шул кешедән кичерүне сорарга).

– ***Аллаһы Тәгаләдән нәрсәдер сорар алдыннан*** ниндидә булса яхшы, ***саваплы гамәл эшләргә*** киңәш ителә (сәдака бирергә, мохтаҗ кешегә ярдәм итәргә һәм башкалар).

– Галимнәр ***дога кылыр алдыннан*** тәһарәт алып ***2 рәкәгать хаҗәт намазы укырга*** киңәш итә.

– ***Дога кылыр алдыннан*** шәхсән үзең өчен нәрсәдер сораганчы, ***Аллаһны мактарга, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмгә салават-шәриф әйтергә*** кирәк. Аннан соң барлык пәйгамбәрләр, сәхабәләр, галим-остазларыбыз, вафат булган туганнарыбыз өчен дә хәер-дога кылып, ахырда гына үз хаҗәтләреңне Аллаһка белдерү хәерле була.

– Сораган нәрсәне бер генә тапкыр түгел – кат-кат сорарга: башка гыйбадәтләр кебек, ***доганың*** да ***дәвамлы булуы мөһим***.

– Кеше авырлык кичергән вакытта Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул итсен өчен, ул ***шатлыклы, тыныч көннәрдә дә Аллаһны онытмаска***, гел шөкер кылып яшәргә тиеш.

– ***Дога кылуның күркәм әдәпләрен*** – дога кылганда ике кулны учлары белән өскә таба юнәлтеп күтәрү, дога кылып бетергәч ике уч белән битне сыпыру һәм ахырда тагын бер кат Аллаһны мактап шөкер сүзләре әйтүне ***истә тоту да әһәмияткә ия.***

**Ришат хәзрәт Курамшин,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире.**

ӘДӘБИ СҮЗ

## Сиңа дәшә күңелем

Коръән дигән изге китап
Безнең өчен язылган.
Барчабызны бәла көтә,
Әгәр аннан тайпылсаң.
Анда түгел гел догалар,
Анда - яшәү рәвеше.
Иминлектә сау-сәламәт
Тыныч яшәү рәвеше.
Туганнарча, дин-кардәшләр
Булып яшәргә, дигән.
Әти-әни кадерләрен
Белеп яшәргә, дигән.
Тагын синең иң якының -
Хәләл җефетең, дигән.
Нурлы йөзе балкып торса,
Имин яшәрсең, дигән.
И Аллаһым, сүзең булып
Изге китабың иңде.
Чиксез рәхмәтләрем сиңа
Барып ирешсен иде.
Коръән алсам кулларыма,
Күзләрдән яшьләр килә.
Сине зикер итә-итә
Тагын яшисем килә.
И Аллаһым, рәхмәт сиңа,
Гомерләр бүләк иттең.
"Әни" дигән сабый сыман,
Сиңа дәшә күңелем...

***Илдар Тимергалин,***
***Кукмара шәһәре.***

# Колак салсаң, үкенмәссең

* Әгәр бер мөселман кеше үзенең мөселман кардәше өчен үзе югында дога кылса, бер фәрештә әйтер: "Аңа сораган нәрсәне Аллаһы Тәгалә үзеңә дә бирсен"

* Кешеләргә явызлык, усаллык кылма, синең шулай эшләвең сиңа үзеңнән сәдака булыр

* Ананың кыз кардәше ана урынына тора

*Хатын-кызга дине, малы яки матурлыгы өчен өйләнелә. Син исә динле булганына өйлән, башкасына исең китмәсен

*Бер куй белән генә булса да туй итегез

*Мөэминнәр арасыннан иң камил иманлылары - күркәм холыклы булганнары, ә арагыздан иң хәерле булганнарыгыз - үз хатынына карата күркәм мөгамәләдә, яхшы мөнәсәбәттә булганыгыздыр

# Күңел ризыгы

Төшке аш якынлашып килә. Өйлә намазыннан соң, авылда картайган Җәүдәт белән Рәхилә өстәл артына утыра. Өстәлдә сыер нигъмәте: ашка катарга катык, каймак, җәймә, ипи күмәче һәм чәй эчәргә дип куелган тагын әллә нәмәрсәләр. Болар өстенә кичә кичтән пешерелгән аш. Икәү генә яшәгәч, Рәхилә ашны ике көнгә бер пешерә. Кичтән пешерә дә, кичне ашап, калганын иртәгә төшкә дип салкынга чыгарып куя. Иртән алар мич күмәче белән каймаклап, баллап чәй эчә. Төшкә – кайнар аш. Рәхиләнең ризыкны җитәрлек хәтле генә пешерү гадәте канына сеңгән. Ике мәртәбә утырып ашарлык дүрт тәлинкә аш. Кайнаганда шулпасы кимесә дип, тагын бер чүмеч шулпа сала. Анысы – Актырнак ризыгы. Атна уртасында бала-чага шәһәрдән кайтып йөрми. Йортта бер сыер да бер эт. Сыер аш ашамый. Инде дә килеп аш әчеп китсә, яисә ашалмыйча калса – Актырнакка бәйрәм. Шулай да әллә ничек күршедәге Шәмҗан апа килеп керсә дип, Рәхилә шулпаны күбрәк куя. Ни дисәң дә ялгыз карчык, берүзенә генә күңелсез. Ара-тирә төш вакытында керә торган гадәте бар Шәмҗанның... Уйлаганың алдыңа килер, ди.

– Ашымны җылытырга куйган җиреннән онытканмын бит, – дип сукрана-сукрана ике тәлинкәгә аш сосканда, ишектә Шәмҗан карчык күренде. Буш кәстрүлен тиз генә аралыкка кертеп куйды да, Рәхилә күрше Шәмҗан карчыкны сәламләде.

– Әйдүк, Шәмҗан апа, әйдүк! Уз әйдә, мактап йөрисең. Аш ашарга җыенып торабыз, – дип өстәл янына күрсәтеп, Шәмҗан карчыкка урын бирде.

– Мин әйтәм, нишләп торалар икән дим. Төнлә утыгыз күренә иде тәрәзәдән. Тиливизорыгыз да эшли иде. Бәйләм бәйләгәнеңне тәрәзәдән күргән идем, – дип Шәмҗан күргәннәрен сөйләп китте.

– Кереп утырасың калган, Шәмҗан апа, – дип җөпләде Рәхилә.

– Кичкә каршы борчып йөрмим дидем инде, якты күздә керермен дип, бүген кәрәсе булдым, – диде карчык.

Өстәл артында утырган Шәмҗан карчык авыл хәлләрен сөйләргә тотынды. Газета алдырасы юк – аяклы газета. Рәхилә өстәл артына утырган Шәмҗан карчыкны кыстарга кереште:

– Шәмҗан апа, бик тәмле аш пешергән идем төнәгенәк. Әйдә бераз гына салыйм әле. Төшке ашны ашамагансыңдыр әле. Бигрәк тәмле, әйдә салыйм әле, – дип кәстрүлдә бер грамм да калмаган аш белән кыстарга кереште Рәхилә. Өстәлдә ике тәлинкә аш барын бар да ул. Берсен Җәүдәткә бирсәм, икенчесен Шәмҗанга бирермен. "Ник, син ашамыйсыңмы дисә, тамагым тук әле, чәй генә эчәрмен", дигән уйларыннан дәртләнеп китеп, тагы да катырак кыстарга кереште.

– Бигрәк тәмле бит, әзрәк сарык ите дә кушкан идем. Ләкшәсен гел йомырка сарысыннан гына баскан идем, – дип кыставын белде Рәхилә.

Күршесе белән хәсрәт-шатлыгын бүлешкән Шәмҗан карчык Рәхиләнең бу эчкерсезлеген белә иде. Авыз чите белән генә елмаеп:

– Рәхмәт, Рәхилә, рәхмәт, тамагым тук, яңа гына йомырка тәбәсе ашаган идем. Ясасаң, бер чынаяк чәеңне эчәрмен мич күмәче белән, – дип авыл хәлләрен сөйләвен дәвам итте.

Төшке аш вакытында күршесенең хәлен белергә кергән Шәмҗан карчыкка бу минутларда җылы сүз, күңел ризыгы тансык иде.

**Гөлфия Насыйбуллина.**

# Бер стакан сөт

***(Танылган Америка докторы Говард Келли турында чын хикәя)***

Беркөнне ярлы гаиләдән булган малай, мәктәптә укыган өчен түләргә акча булсын, дип ишектән-ишеккә йөреп, әйберләр сатып йөргән. Көн бик салкын, яңгырлы – вактөяк товарын да алучы юк. Тамагы ачып, кесәсен актарып карый – анда тамак ялгарлык акча табылмый. «Менә бу йорт хуҗасыннан ашарга сорап карармын», – дип уйлый, ләкин ишекне бик матур яшь кыз ачкач, малай югалып кала һәм бер стакан су гына сорый. Сөенечкә, аңа бер стакан җылы сөт алып чыгып бирәләр. Аның тәмлелеген әйтеп бетерә торган түгел! «Күпме түләргә тиеш мин сезгә?» – дигән сорауга, – «Бер тиен дә түгел. Әнием эшләгән яхшылык өчен түләүне беркайчан да алмаска өйрәтте...» Чын күңелдән булган рәхмәтен белдереп, малай үзенә хәл кергәнен сизеп, бар кешеләргә, дөнья Хуҗасына ышанычы ныгып китә.

Күпмедер еллар үткәч, Американың бер зур шәһәренең хастаханәсенә каты авыру яшь хатынны алып киләләр. Бик танылган, операцияләр өчен, гадәттә, кыйммәтле түләү хакын сораган доктор Говард Келли аның кайсы шәһәрдән килгәнен ишеткәч, авыруның палатасына керә һәм үлем хәлендә булган ханымда теге яшь кызны таный. Дәвалауга бөтен көчен куеп, доктор аны үлемнән коткара. Операция өчен түләргә вакыт җиткәч, авыру хатын бик борчыла: калган бөтен гомере буена эшләгән бар акчасы шушы дәва өчен түләүгә китәчәк. "Күпме түләргә тиеш мин сезгә?" – дип сорый."Бер тиен дә түгел". "Дәвалану хакын әйтегез!" "Бер стакан сөт..." "Барысы да аңлашылды... " Күзләренә яшь тулган хатын: «Йа Раббым, чиксез рәхмәт Сиңа, Синең мине яратуың шәфкатьле кешеләрнең йөрәге һәм куллары аша миңа җиткерелде!» – дип елый...

## МИНЕМ ФИКЕР



**Эльмира Гыйләҗева,** *"Хәләл Үзәк"тәге "Әл-Каләм" кибете сатучысы:*

Мөселман кешесе өчен бүген бүләк сайлау артык катлаулы мәсьәлә түгел. Әйтик, безнең бүлеккә ислам дөньясына караган китаплар эзләп тә, бүләк алырга дип тә еш керәләр. Кибетебездә Коръәннең төрле басмалары бар, Коръәнне укырга өйрәтү, фикх, гакыйдә һәм башкаларны үз эченә алган дәреслекләребез дә, балалар өчен китапларыбыз да җитәрлек. Моннан тыш, һәртөрле сувенирлар, косметика, намазлыклар, савыт-саба, сәгатьләр, Дубайдан, Согуд Гарәбстаныннан, Египеттан кайтарылган хушбуйлар, ислемайлар да менә дигән бүләк булып тора. Күчтәнәчкә тәмле чәй, финиклар, сыйфатлы бал кирәк диючеләргә аларны да рәхәтләнеп тәкъдим итә алабыз. Соңгы елларда күпләр, дини мәҗлесләрдә тарату өчен тәсбихләр, кечкенә форматтагы китапчыклар юкмы, дип мөрәҗәгать итәләр - кибетебездә алар да бар. Шәмаил кирәк иде дип килүчеләргә дә сайлау мөмкинлеге зур. Анда язылган аятьләрнең мәгънәсен аңлап, белеп, үзең укып йөрү кирәклеген дә төшендерергә онытмыйбыз. Сүз уңаеннан шунысын да әйтергә мөмкин - бездә ир-ат һәм хатын-кызлар өчен мөселман киемнәре дә бар. Гомумән, бүгенге көндә кечкенә генә бүләк-күчтәнәч белән дә якыннарыңа олы сөенеч китерү авыр түгел, иң мөһиме - ризыкларыбыз хәләл, бүләкләребез Аллаһы Тәгаләгә якынаюда файда китерердәй савaплы булсын.



## Яңа китаплар



Хөрмәтле дуслар!

Чаллыдагы "Ислам нуры" нәшриятында яңа китаплар даими дөнья күреп тора. Алла боерса, газета битләрендә без алар белән укучыларыбызны да таныштырып барырбыз. Күптән түгел генә, Кукмара мәдрәсәсенең 20 еллык юбилеена туры китереп, әлеге мәдрәсәнең мөдире Ришат Курамшинның "Күңел күзе" дип аталган әр-яңа китабы басылып чыкты. Анда 2018 елда язылган хикәяләр, шигырьләр урын алган. Шушы ике бүлектән тыш "Кыска, ләкин олы мәгънәле Хикмәтләр" дигән кызыклы бүлек тә бар. Китапны Кукмара мәдрәсәсеннән, шулай ук дини китаплар сатыла торган мөселман кибетләреннән алырга була. Күпләп алырга теләүчеләр булса, турыдан- туры Чаллыдагы "Ислам нуры" нәшриятына мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Телефоны - 8 (8552) 70-51-45. Китапка тупланган тирән эчтәлекле, мәгънәле хикәяләр уйланырга, тормыш сабакларыннан гыйбрәт һәм үрнәк алырга этәргә; үзегез өчен дә, якыннарыгыз өчен дә менә дигән бүләк булып тора.

*Балалар өчен*

## Золым кылма

Балам, золым кылма!
Кылма беркайчан золым!
Кешене рәнҗетмә,
Малына аның тимә!

Балам, золым кылма!
Шайтан юлыннан барма!
Яхшыны боерды,
Аллаһ золымны тыйды.

Балам, золым кылма!
Тугры юлдан адашма!
Пәйгамбәр кисәтте,
Хәдисләрендә әйтте.

Балам, золым кылма!
Эшләмәсәң дә файда,
Гел тыел золымнан,
Файда кылырсың
соңыннан!

Балам, золым кылма!
Ят кешеңә, дустыңа!
Балам, золым кылма!
Бул имин барсына.

**Алинә Әхмәдишина,**
**"Асыл зат" төркеме җитәкчесе.**



**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1350**
**Индексы 54149**
* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды: график буенча**
**25 гыйнвар 16 сәг.**
**фактта 25 гыйнвар 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**